**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзү турында» 2017 елның 26 маендагы ПУ-441 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 22 декабрендәге ПУ-1153 номерлы һәм 2018 елның 19 февралендәге ПУ-177 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Россия Көнен һәм Татарстан Республикасы Көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) оештыру комитеты составыннан В.Г. Шәйхразиевны, А.М. Сибагатуллинны чыгарырга;

б) оештыру комитеты составына Әюпова Ирада Хафизҗан кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын кертергә;

в) оештыру комитеты әгъзасы Л.Р. Фазлыеваның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары», аны оештыру комитеты рәисе урынбасары итеп расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 06 июнь
№ ПУ-406